# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**«Татарстан Республикасы каршында аерым казанышлары булган гражданнарның дәүләт пенсиясенә өстәмә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

**1 статья.** «Татарстан Республикасы каршында аерым казанышлары булган гражданнарның дәүләт пенсиясенә өстәмә турында» Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, №3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 3 статьяның дүртенче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Өстәмә хезмәт өчен түләүнең Татарстан Республикасында билгеләнгән биш минималь күләменнән артык булмаган күләмдә дәүләт пенсиясе алучы гражданнарга билгеләнә.».

2. 9 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9 статья. Өстәмә түләү чаралары

Гражданнарга өстәмә түләү түбәндәге чаралардан башкарыла:

Татарстан Республикасының Республика бюджетыннан;

җирле бюджетларның дәүләт хакимияте һәм идарәсе җирле органнары карары нигезендә дәүләт пенсияләренә өстәмә түләү өчен максатчыл билгеләнештә җибәрелә торган акчаларыннан;

предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмаларның билгеләнгән тәртиптә өстәмә түләү өчен җибәрелүче акчаларыннан;

законнар белән тыелмаган башка төрле чыганаклардан.

252

Керүче акчалар дәүләт пенсияләре түләү буенча Татарстан Республикасы буенча вәкаләтле орган счетына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә күчерелә.».

**2 статья.** Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

М.Шәймиев

Казан шәһәре,
2001 елның 25 октябре
№ 1140